РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 05 » 06 2023 г. №809

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 декабрендәге 962 номерлы карары белән расланган “2021-2024 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Ютазы муниципаль районының комплекслы программа”сына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Конституциясенә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 декабрендәге 962 номерлы карары белән расланган 2021-2024 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Ютазы муниципаль районының комплекслы программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Комплекслы программаның 2 бүлегенең 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе указларын һәм Татарстан Республикасы законнарын, федераль һәм республика программаларын, шул исәптән җинаятьчелеккә каршы көрәш, наркотиклаштыруны профилактикалау, мәшгуль булмаган халыкны эш белән тәэмин итүгә һәм социаль яклауга ярдәм итү, яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү һәм психологик ярдәм күрсәтү системасын үстерү буенча указларны гамәлгә ашыру, шулай ук полициянең участок уполномоченныйлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм аларны социаль-хокукый яклау дәрәҗәсен күтәрү буенча күрелә торган чаралар Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районында иҗтимагый иминлек торышын тотрыклыландыруга ярдәм итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина